**Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы ТүбәнУратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2019елның12 ноябре№ 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2018 елның 5 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Уратма торак пунктында юлларны ремонтлау

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 617 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 318 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 318 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Уратма авыл җирлеге составына керүче Түбән Уратма торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Түбән Кама муниципаль районының Түбән Уратма авыл җирлеге Түбән Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле

әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Уратма торак пунктында юлларны ремонтлау»
мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныРга.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Түбән Уратма авыл җирлеге сайтында һәмТүбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы беләнигъланитәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертүөчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Түбән Уратма авыл җирлеге башлыгы А.Р.Гарифуллин